ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.09.2019 г. Заинск № 483

**« Татарстан Республикасының Зәй муниципаль районында хокук бозуларны кисәтү өлкәсендә Координация советы турында»**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» (6 октябрь, 2003 ел) 131нче федераль закон, «Россия Федерациясендә хокук бозуларны кисәтү системасы нигезләре турында” (23 июнь, 2016 ел) 182нче федераль закон, Татарстан Республикасында хокук бозуларны кисәтү турында (11 гыйнвар, 2017 ел), 3нче Татарстан Республикасы законы, “Татарстан Республикасы террриториясендә корал, сугыш кирәк-яраклары, коралга патроннар, шартлату җайланмалары, шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнешен кисәтү буенча чаралар турында” (5 август, 1995 ел) 545нче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары һәм Зәй муниципаль районы Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә**:

1.Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында хокук бозуларны кисәтү өлкәсендә Координация советы төзергә һәм аның составын расларга (1нче кушымта).

2.Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында хокук бозуларны кисәтү өлкәсендә Координация советы турында Положениене расларга.

3.Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә элеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырырга, “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында” httr://pravo. tatarstan. ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5.Карарның үтәлешенә күзәтчелек итүне муниципаль районның Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.В.Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Л.Г. Федотова
7 52 84

Зәй муниипаль районы башкарма комитетының
"10" 09 2019 ел 483 нче карарына
1нче кушымта

# Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында хокук бозуларны кисәтү өлкәсендә Координация советы составы

Илнар Фәнил улы Хафизов – Муниципаль район Башкарма комитеты житәкчесе,

Координация советы рәисе

Александр Владимирович Чапков – Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, Координация советы рәисе урынбасары

Лариса Григорьевна Федотова – Башкарма комитетның яшьләр эшләре идарәсе башлыгы, Координаия советы сәркатибе

**Координация советы әгъзалары:**

Айрат Фоат улы Әгъләмжанов – шәһәр-район хәрби комиссары

Илфат Зиннур улы Әшрәпов - башкарма комитетның физик культура, спорт һәм туризм буенча идарәсе башлыгы

Игорь Александрович Биканов – кеше хокуклары буенча Татарстан Республикасы вәкаләтлесенең район җәмәгатчелек ярдәмчесе (килешу буенча)

Игорь Викторович Будрин - Район суд приставлары бүлеге башлыгы – өлкән суд приставы

Дина Леонидовна Бушуева – Бала хокуклары буенча Татарстан Республикасы вәкаләтлесенең район җәмәгатьчелек ярдәмчесе (килешү буенча)

Альмира Габделхак кызы Галләмова – Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча район комиссиясенең жаваплы сәркатибе

Раил Разиф улы Гарифуллин –Федераль куркынычсызлык хезмәтенең район бүлеге башлыгы

Разил Разиф улы Гыймадиев - Росгвардия идарәсенең Татарстан Республикасы буенча Түбән Кама шәһәре лицензия-рөхсәт бирү бүлекчәсе өлкән инспекторы

Андрей Васильевич Иванов - Россия җәза үтәтү инспекциясенең Татарстан Республикасы буенча Зәй филиалы башлыгы

Рамил Хәертдин улы Исмәгыйлев - Зәй районара тикшерү бүлеге житәкчесе

Венера Назыйф кызы Исрафилова – "Татмедиа" АҖнең "Зәй-информ" филиалы җитәкчесе (килешү буенча)

Ольга Викторовна Лаптева – Шәһәр-район мәшгульлек үзәге директоры вазифаларын башкаручы

Лилия Равил кызы Печина – Башкарма комитетның мәгариф идарәсе башлыгы

Андрей Борисович Пичкалов – күзәтчелек эшчәнлеге буенча бүлек башлыгы вазифаларын башкаручы (килешү буенча)

Светлана Юрьевна Ревина - Башкарма комитетның мәдәният идарәсе башлыгы

Татьяна Викторовна Токмакова – Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча район башлыгы ярдәмчесе

Галина Алексеевна Усманова- Федераль миграция хезмәтенең Зәй районы бүлеге башлыгы

Айдар Назыйф улы Фәсхетдинов – Шәһәр-район эчке эшләр бүлеге башлыгы

Ирина Петровна Фәттахова – Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы

Илмир Рамил улы Хәйретдинов – Шәһәр-район эчке эшләр бүлегенең балигъ булмаганнар белән эшләү бүлекчәсе башлыгы

Эльмира Габделхак кызы Хуҗина - Район социаль яклау бүлеге башлыгы

Зәй мунниипаль районы башкарма комитетының
“10” 09 2019 ел 483 нче карарына
2нче кушымта

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында хокук бозуларны кисәтү сферасында Координация советы төзү турында
ПОЛОЖЕНИЕ

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1 Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында хокук бозуларны кисәтү сферасында Координация советы (алга таба – Координация советы) хокук бозуларны кисәтүдә көйләүче орган булып тора һәм гражданнарга, оешмаларга кеше һәм гражданин хокуклары һәм ирекген яклауны тәэмин итү, җәмгыять һәм дәүләтне хокукка каршы кул сузулардан саклауга юнәлтелгән мәгълүмат җиткерү, шулай ук комплекслы чаралар - тормышта кыен хәлгә калганнарга ярдәм күрсәтү, аларның конституцион хокуклары һәм ирекләрен тормышка ашыруда, эшкә урнашу һәм көнкүрешен көйләүдә булышу, ирektән мәхрүм итү урыннарыннан кайтучыларны яки җинаять- хокук характерындагы башка гамәлләргә дучар булганнарны ресоциализацияләү, авыр тормыш хәлендә калганнарны тернәкләндерү, хокук бозулардан зыян күргән яки шул юлга кереп китү куркынычы булганннарга ярдәм итүне күз алдында тота.

1.2 Координация советы үз эшчәнлеген башкарма властьнең федераль, Татарстан Республикасы органнары, жирле хокук саклау органнары, төрле милек формасындагы оешма, предприятие, учреждениеләр, иҗтимагый оешмалар, ассоциацияләр фондлар һәм гражданнар белән берлектә гамәлгә ашыра.

1.3 Координация советы үз эшендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституция законнарына, “Россия Федерациясендә хокук бозуларны кисәтү системасы нигезләре турында” (23.06.2016) 182нче федераль законга, башка федераль законнарга, шулай ук аларга туры китереп кабул ителгән Россия Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте, башкарма власть федераль органнары норматив-хокук актларына, Татарстан Республикасы законнарына, башка норматив-хокукый актларга, муниципаль дәрәҗәдәге хокук актларына һәм әлеге Положениегә нигезләнә.

**2. Профилактик тәэсир итүнең төп формалары**

2.1 Координация советының профилактик тәэсир итү формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) хокукый аң-белем һәм хокукый мәгълүмат бирү;

2)социаль адаптацияләү;

3) ресоциализацияләү
4) соиаль тернәкләндерү;
5)хокук бозудан зыян күргәннәргә яки шул юлга кереп китү куркынычы булганнарга ярдәм итү;
6) балигъ булмаган яшьтәгеләрнең күзәтчесезлеген, тәрбиячесезлеген, хокук бозуын һәм җәмгыятькә каршы тискәре гамәлләр кылуын кисәтү;
7) гражданнарның хокукый грамоталылык дәрәҗәсен күтәрү һәм хокукый аңын үстерү.

2. Координация советы үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү максатында түбәндәге функицяләрне башкара:

- хокук бозуларны кисәтүдә өстенлекле юнәлешләрне, максат һәм бурычларны билгеләү максатында мәгълүмат җыю һәм анализлау, криминоген хәл үзгәрүне исәпкә алып, тәкъдимнәр һәм киңәшләр эшләү;
- хокук бозуларны кисәтү һәм җинаятьчелек белән көрәштә норматив-хокук актлары, программалар, проектлар эшләү һәм аларны кабул итү буенча тәкъдимнәр әзерләү;
- район биләмәсендәге җәмәгать тәртибен саклау буенча гра;даннарның иҗтимагый төзелмәләренә методик ярдәм күрсәтү;
- профилактика эше буенча тәҗрибә уртаклашуны оештыру;
-“Татарстан Республикасында дәүләт муниипаль хезмәтләре күрсәтүнең күпфункцияле үзәге” һәм аның филиалларыннан кергән документлар нигезендә нәтиҗәләр ясау.

2.3 Координация советы үз компетенциясе кысаларында түбәндәгеләргә хокуклы:

- башкарма власть органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрдән совет эше өчен кирәкле материал һәм мәгълүматларны соратып алырга;
- утырышларда башкарма власть органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре чыгышларын тыңлауга куярга;
- уз эшләрендә катнашуга башкарма власть органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр вәкилләрен җәлеп итәргә (килешү буенча);
- эшчәнлекнең аерым юнәлешләре буенча яки хокук бозуларны кисәтү өлкәсендә анык проблемаларны хәл итүдә эшче төркем төзергә.

**3. Координация советының составы**

3.1 Координация советының составы башкарма комитет карары белән раслана.

Совет составына җирле үзидарә органнары вәкилләреннән тыш, хокук саклау органнары ( полициянең участок вәкаләтлеләре) лицензия-рөхсәт бирү эшләре бүлеге, ирекле халык дружинасы, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр, дини оешмалар, социаль яклау органнары, мәгариф, мәдәният өлкәсе вәкилләре, шулай ук җирлек гражданнарының актив өлеше кертелергә мөмкин

3.2 Координация советы совет рәисе, урынбасар, сәркатип һәм әгъзалардан тора.

3.3 Координация советы рәисе булып, эшчәнлек белән идарә итүче һәм аңа йөкләнгән бурычлар өчен җаваплылык тотучы Башкарма комитет җитәкчесе тора.

## 4. Координация советы эшен оештыру

4.1. Координаия советы эшен җәмәгат башлангычында алып бара.

4.2 Координация советын рәис җитәкли, ул булмаганда, аны урынбасар алмаштыра.

4.3. Координация советы составына хокук бозуларны профилактикалау эшен гамәлгә ашыручы территориаль җирле үзидарә органнары вәкилләре керә.

4.4 Координация советы эше рәис раслаган план нигезендә алып барыла.

4.5. Утырышлар, мөһимлектән чыгып, кварталга бер мәртәбәдән дә ким үткәрелми һәм утырышта совет әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашканда гына тулы хокуклы була.

4.6 Утырышка материалларны көн тәртибендәге мәсьәлә кагылган власть органнары , оешмалар вәкилләре әзерли. Материаллар утырышка кадәр 10 көн алдан күрсәтелә.

4.7 Карарлар утырышта катнашучы әгъзаларның күпчелеге тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч рольне уйный.

4.8 Координация советы әгъзаларының утырышта катнашуы мәҗбүри. Совет әгъзасы утырышта катнаша алмаганда, карала торган мәсьәлә буенча үз фикерен язмача белдерергә хокуклы. Совет әгъзасы утырышта катнаша алмаганда , ул бу турыда рәискә хәбәр итә.

4.9 Карарлар беркетмә белән формалаштырыла һәм аларга рәис белән сәркатип кул куя.

4.10 Координация советы утырышларында прокуратура, суд органнары вәкилләре катнаша ала.

4.11 Координация советы рәисе:

4.11.1 эш оештыра, планны раслый, утырышны алып бара.

4.11.2 утырыш беркетмәсен имзалый.

4.11.3 совет әгъзалары арасында вазифаларны бүлә.

4.11.4 совет компетенциясенә кергән мәсьәләләрне хәл итеп бетерү өчен эшче төркем төзи һәм аларның эшенә күзәтчелек итә.

4.11.5 Совет компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча мәнфәгатьләрне кайгырта.

4.12 Совет сәркатибе: координация советы эш планнары проектын әзерли, аларны гамәлгә ашыруны күзәтә, шулай ук утырышка кирәкле документлар һәм аналитик материаллар әзерли, утырышларның билгеләнгән вакытта үткәрелүен тәэмин итә.

4.12.2 Координация советы утырышлары беркетмәләрен формалаштыра, алар нигезендә эшне контролдә тота.

4.12.3 эш планына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча, шулай ук эшне оештыру мәсьәләләрендә рәискә тәкъдимнәр бирә.

4.13. Координация советының оештыру-техник тәэмин ителешен Башкарма комитетның оештыру бүлеге гамәлгә ашыра.